**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

ПРИКАЗ

03.11.2016 г. Казань № 077-од

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне куллануга бәйле булган, билгеләп куелганда конкурс уздырмау мөмкин булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль закон һәм Вазыйфаи затларга һәм Россия Федерациясе гражданнарына дәүләт серен файдалануны рөхсәт итү тәртибе турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 6 февралендәге № 63 карары белән расланган инструкция нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне куллануга бәйле булган, билгеләп куелганда «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль законның 22 статьясындагы 3 өлеше нигезендә конкурс уздырмау мөмкин булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Хокук һәм кадрлар эше бүлеге башлыгы В.Г. Миңнеәхмәтова әлеге борыкны дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә тиеш.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт комитетының
03.11.2016 №077-од
боерыгына кушымта

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне куллануга бәйле булган, билгеләп куелганда конкурс уздырмау мөмкин булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Рәис урынбасары
2. Хокук һәм кадрлар эше бүлеге башлыгы
3. Финанс-икътисадый бүлек башлыгы
4. Дәүләт контроле секторы мөдире
5. Архив тармагын мәгълүматлаштыру секторы мөдире
6. Хокук һәм кадрлар эше бүлегенең әйдәүче киңәшчесе
7. Мобилизацион эш буенча өлкән белгеч